Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылы торак пунктында
гражданнар җыены КАРАРЫ

«15»март 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылы территориясендә яшәүче, 1 гр. инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның тол калган хатыннарыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан кала балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы торак пункты чикләрендә юл полотносы профилен үзгәртеп, юлларны карап тоту, вак ташлар сатып алу, юл полотносы профилен үзгәртү өчен хезмәт күрсәтү.

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы торак пункты чикләрендә юлларны карап тоту, грейдировкалау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм алга таба таш җәю өчен тыгыз нигез салу,

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы территориясен чистарту һәм төзекләндерү

Халык җыенында рәислек итүче Р.Г. Хисамов

Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хисамов